**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2025 Балык Бистәсе штп. №54пг

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтнамә бирү турында боерыгы проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары уздыруны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтнамә бирү турындагы боерыгы проекты буенча кадастр номеры 16:34:150102:661 булган 1713 кв. м мәйданлы Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Масловка авыл җирлеге, Масловка авылы, Үзәк урам, 57А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәхси торак төзелеше зонасындагы (Ж1) «Кунакханә хезмәте күрсәтү» җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтнамә бирү буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын билгеләргә.

2. Билгеләргә (анычкларга):

2.1. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетын (алга таба – җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыручы).

2.2.Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6

октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәдә тәгаенләнгән тәртип нигезендә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын 2025 елның 3 февраленнән 2025 елның 10 февраленә кадәрге чорда уздыруны.

2.3. Проект экспозициясен урнаштыру (үткәрү) урыны итеп Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Масловка авылы, Үзәк урам, 13 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советы бинасын, эш көннәрендә 8 сәгатьтән 12 сәгатькә кадәр 2025 елның 3 февраленнән 2025 елның 10 февраленә чаклы; Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтын https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/gradostroitelstvo.htm. Тәкъдимнәр, искәртүләрне 2025 елның 3 февраленнән башлап 2025 елның 10 февраленә чаклы эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәг.кә кадәр язма рәвештә һәм (яки) Irek.Hamidullin@tatar.ru электрон почтасына кабул итәргә.

3.Җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыручыга проект буенча җәмәгатьчелек фикер алышулар уздыру турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башкарма комитетына мәгълүматлар соратыла торган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә җиткерү өчен хәбәр җибәрергә.

4. Мөрәҗәгать итүче Семенова Елена Анатольевнага җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыруны техник яктан тәэмин итәргә, шул исәптән экспозицияне уздырганда һәм әлеге рөхсәтнамә соратыла торган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә җиткергәндә.

5. Җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыручыга:

5.1. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын үткәрүне тәэмин итәргә.

5.2. Проектлар буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары башлану турында хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советы бинасында җиһазландырылган мәгълүмат стендында һәм Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/gradostroitelstvo.htm.

5.3. 2025 елның 3 февраленнән дә соңга калмыйча Балык Бистәсе муниципаль районының https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/gradostroitelstvo.htm рәсми сайтында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтнамә бирү турындагы боерыгы проекты буенча кадастр номеры 16:34:150102:661 булган 1713 кв. м мәйданлы Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Масловка авыл җирлеге, Масловка авылы, Үзәк урам, 57А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәхси торак төзелеше зонасындагы (Ж1) «Кунакханә хезмәте күрсәтү» җир кишәрлегеннән файдаланунның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтнамә бирү турында боерык проектын урнаштырырга.

5.4. Әлеге карарның 5.3 пунктында күрсәтелгән проектлар буенча экспозицияләрне 2025 елның 3 февраленнән 2025 елның 10 февраленә чаклы эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка авыл җирлеге Советы бинасында оештырырга, шулай ук шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында https://ribnaya - sloboda.tatarstan.ru/gradostroitelstvo.htm.

5.5 Җәмәгатьчелек фикер алышулары тәмамлангач, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/gradostroitelstvo.htm җәмәгатьчелек фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләп урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://ribnaya - sloboda.tatarstan.ru.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов